***РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН***
ГЛАВА
Чалпинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д.39, с. Чалпы, 423324
Азнакаевского муниципального района
Тел. (8-5592) 35-5-46,
факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

***ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ***
Азнакай
муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге
Советы
БАШЛЫГЫ

Үзәк урам, 39, Чалпы авылы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46,
факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«16» ноябрь 2023 ел. №7

Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы,
Чалпы авылы, Ленин урамы, 111 йорт,
Ирекле авылы, Гагарин урамы, 32 йорт,
Ирекле авылы, Гагарин урамы , 34 йорт адреслары буенча
урнашкан җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга
рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами
тыңлауларны билгеләү турында

Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча Чалпы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең яшәү шартлары, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре уңай шартларын үтәү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Чалпы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре, Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә **карар бирә**:

1. Җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләргә:

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Ленин урамы, 111 йорт адресы буенча урнашкан 1614 кв.м.мәйданлы 16:02:130101:339 кадастр номерлы булган - бакчачылык алып бару (код 13.1) - шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1).
- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Ирекле авылы, Гагарин урамы, 32 йорт адресы буенча урнашкан 2077,16 кв.м.мәйданлы 16:02:130301:42 кадастр номерлы булган - бакчачылык алып бару (код 13.1) - шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1).
- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Ирекле авылы, Гагарин урамы, 34 йорт адресы буенча урнашкан 1940,81 кв.м.мәйданлы 16:02:130301:43 кадастр номерлы булган - бакчачылык алып бару (код 13.1) - шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1).

2. Билгеләргә:

- халык тыңлауларын оештыручы итеп - Чалпы авыл җирлегендә җирдән файдалану

һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссияне;

- үткәрү вакыты - 2023 елның 27 ноябреннән 2023 елның 11 декабренә кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны – Чалпы авылы, Үзәк урам, 39 йорт адресы буенча урнашкан Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы.

- 2023 елның 11 декабренә кадәр тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Чалпы авылы, Үзәк урам, 39, Азнакай муниципаль районының Чалпы авылы җирлеге Башкарма комитеты.

3. Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиясенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 28 ноябренә кадәр, җир кишәрлеге белән гомуми чикләре булган җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртүгә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турындагы хәбәрләрне җибәрергә;

- җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытта рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында нәтиҗә әзерләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче: Мөхәмәтшин А.М.